Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.** |

1. Кайсы шагыйрь татар милләтенең киләчәген таң белән чагыштырган?
   1) С.Рәмиев
   2) Дәрдемәнд
   3) Н.Думави

2. Әлеге әдипләр арасыннан суфи шагыйрьне билгеләгез:
   1) Кол Гали
   2) Мәүла Колый
   3) Сәйф Сараи

3. Г. Тукай иҗат иткән «Милли моңнар» әсәренең жанрын билгеләгез:
   1) мәхәббәт лирикасы
   2) гражданлык лирикасы
   4) фәлсәфи лирика

4. «Гыйлемнең өстенлеге турында» шигыренең авторы:
   1) Сәйф Сараи
   2) Г.Утыз-Имәни
   3) Мәүлә Колый

| |
|---|
| **5 – 7 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.** |

5. Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» әсәре кайсы әдәби төргә карый:

   Җавап: ________________

6. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Кыйссаи Йосыф» | 1) Г.Кандалый |
| Ә) «Сәхипҗәмалга» | 2) Сәйф Сараи |
| Б) «Сөһәйл вә Гөлдерсен» | 3) Кол Гали |

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *шигырь, дастан, поэма* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Сөһәйл вә Гөлдерсен»
2) «Гафил торма»
3) «Идегәй»

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**8 – 11 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

8. М.Акъегетзадәнең«Хисаметдин менла» әсәре караган әдәби төрне билгеләгез:

1) проза
2) драма
3) лиро-эпика

9. Әдәбиятның «алтын чоры» буларак билгеләнгән чорны күрсәтегез:

1) XIX гасыр
2) XX гасыр башы
3) совет чоры әдәбияты

3. Ф.Әмирханның «Хәят» повестенда Хәятнең кичерешләре нинди алым белән бирелә?

1) психологизм
2) символлаштыру
3) лиризм

11. *«Гөлйөзем әбин һәркөнне әллә ничә мәртәбә идәнне себерә, һәр атнакич ком берлән сап-сары итеп самавырны ача, айда бер өйнең ярыкларын ямар өчен сылаган балчык өстеннән акбур берлән буйый, һәр намаз алдыннан картының комганына су сала иде»*өзеге кайсы әсәрдән алынган:

1) Г.Исхакый «Сөннәтче бабай»
2) Ф.Әмирхан «Хәят»
3) Г.Исхакый «Көз»

**12-14 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

12. Ф.Әмирханның «Хәят» әсәренең жанры:

Җавап: ________________

13. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Хисметдин менла» | 1) Ф.Әмирхан |
| Ә)«Хәят» | 2) Г.Исхакый |
| Б) «Сөннәтче бабай» | 3) М.Акъегетзадә |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз..

14. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *шигырь, роман, повесть* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Хәят»
2) «Кәсеп турында»
3) «Хисаметдин менла»

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**15.1 һәм 15.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

15.1. Г.Исхакыйның «Сөннәтче бабай» повестеннан өзекне тыңлагыз. Гөлйөзем әбинең төп сыйфаты нинди?

15.2. Дәрдемәнднең «Кораб» шигырендә символик образлар аша нинди фикерләр җиткерелә?

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 2 |
| 3 | 2 |
| 4 | 2 |
| 5 | ПОЭЗИЯ / ЛИРО-ЭПИКА |
| 6 | 312 |
| 7 | 231 |
| 8 | 1 |
| 9 | 2 |
| 10 | 1 |
| 11 | 1 |
| 12 | ПОВЕСТЬ |
| 13 | 312 |
| 14 | 231 |

**Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары**

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |

| | |
|---|---|
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**8 нче сыйныф татар укучыларына татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Күрсәтмә вариантка аңлатма**

Татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты укучыларга һәм укытучыларга йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга тест эшләүгә мөстәкыйль әзерләнү өчен юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда биремнәрнең структурасы, күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм укытучыларда бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый, укучыларга татар әдәбиятыннан тестларга әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итә.

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Имтихан эшен башкару өчен 45 минут вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан тест уздыру биремнәре 15 биремне үз эченә алган 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлектәге биремнәр лирик яки лиро-эпик әсәргә, аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның лирик яки лиро-эпик әсәргә яки шагыйрь иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Икенче бүлектәге биремнәр проза яки драма әсәренә һәм аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның эпик яки драматик әсәргә яки әдип иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, проза яки драма әсәрләренә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә. Җавап бирү барышында төгәл эшләү һәм күрсәтмәләрне игътибар белән уку таләп ителә.

Өченче бүлектәге биремнәр 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап язуга йөз тота. Ике сорауның сайлап алып БЕРСЕНӘ генә җавап бирү сорала. Җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә формалаштыру кирәк. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Беренче, икенче бүлекләрдә сорауга төгәл җавап табылмый икән, авырлык тудырган сорауларны калдырып торырга, өченче өлештәге биремне үтәргә, эшләнми калган биремнәргә соңыннан әйләнеп кайтырга мөмкин.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

**1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

1. Лирикада сөйләүче герой кем дип атала?
    1) Лирик герой яки лирик «мин»
    2) хикәяләүче
    3) автор

2. «Кеше кайчан матур була?» шигыренең авторы кем?
    1) Н.Арсланов
    2) Р.Харис
    3) Р.Гаташ

3. Г.Моратның «Туган тел» шигыре нинди жанрга карый?
    1) Пейзаж лирикасына
    2) Фәлсәфи лирикага
    3) Гражданлык лирикасына

4. Әсәрләр арасыннан композитор язмышы турындагысын килгәнен билгеләгез:
    1) «Сәйдәш»
    2) «Тукайга»
    3) «Буранда»

**5 – 7 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

5. «Кеше кайчан матур була?» шигыренең авторы кем? Исем-фамилиясен языгыз:

Җавап: ________________

6. Әсәрне һәм аның жанрын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Кайсыгызның кулы җылы» | 1) Пейзаж лирикасы |
| Ә) «Халкыма» | 2) Күңел лирикасы |
| Б) «Җәйге таң хатирәсе» | 3) Гражданлык лирикасы |

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз..

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *шигырь, хикәя, поэма* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Сәйдәш»
2) «Туган тел»
3) «Буранда»

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**8 – 11 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

8. «Мөһаҗирләр» романында милләт анасы образы кем?

1) Әсма
2) Хәтирә
3) Саҗидә

9. Сюжеттан тыш элементны атагыз.

1) экспозиция
2) кульминация
3) лирик чигенеш

10. «Буранда» хикәясендә кайсы образ Мостафаның ачарга ярдәм итә?

1) ана
2) буран
3) тарантас

11. «Әлдермештән Әлмәндәр» әсәренең жанры:

1) моңсу комедия
2) драма
3) трагедия

**12-14 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында**

**буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

12. Эпик әсәрдә сөйләүче герой кем дип атала:

Җавап: _______________

13. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз.

| | |
|---|---|
| А) «Сәлам» | 1) Г.Бәширов |
| Ә) «Туган ягым – яшел бишек» | 2) М.Мәһдиев |
| В) «Без – кырык беренче ел балалары» | 3) Р.Галиуллин |

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

14. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *хикәя, повесть, шигырь* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Без – кырык беренче ел балалары»
2) «Татар китабы»
3) «Буранда»

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**15.1 һәм 15.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

15.1. Ш.Камалның «Буранда» хикәясеннән өзекне тыңлагыз. Сурәтләнгән вакыйгада һәркем өчен уртак булган хис нинди? Ачыклап языгыз.

15.2. Р.Харисның «Кеше кайчан матур була» шигырен тыңлагыз. Матур булу өчен нинди сыйфатларга ия булырга кирәк, ди лирик герой?

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 2 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1 |
| 5 | РЕНАТ ХАРИС |
| 6 | 231 |
| 7 | 231 |
| 8 | 3 |
| 9 | 3 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | ХИКӘЯЛӘҮЧЕ |
| 13 | 312 |
| 14 | 312 |

**Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары**

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |

| | |
|---|---|
| **Иң югары балл** | **3** |

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**5 нче сыйныф татар укучыларына татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

**Күрсәтмә вариантка аңлатма**

Татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты укучыларга һәм укытучыларга йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга тест эшләүгә мөстәкыйль әзерләнү өчен юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда биремнәрнең структурасы, күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм укытучыларда бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый, укучыларга татар әдәбиятыннан тестларга әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итә.

**Эшне башкару өчен күрсәтмә**

Имтихан эшен башкару өчен 45 минут вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан тест уздыру биремнәре 13 биремне үз эченә алган 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлектәге биремнәр лирик яки лиро-эпик әсәргә, аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның лирик яки лиро-эпик әсәргә яки шагыйрь иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 3 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Икенче бүлектәге биремнәр проза яки драма әсәренә һәм аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның эпик яки драматик әсәргә яки әдип иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, проза яки драма әсәрләренә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 3 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә. Җавап бирү барышында төгәл эшләү һәм күрсәтмәләрне игътибар белән уку таләп ителә.

Өченче бүлектәге биремнәр 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап язуга йөз тота. Ике сорауның сайлап алып БЕРСЕНӘ генә җавап бирү сорала. Җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә формалаштыру кирәк. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Беренче, икенче бүлекләрдә сорауга төгәл җавап табылмый икән, авырлык тудырган сорауларны калдырып торырга, өченче өлештәге биремне үтәргә, эшләнми калган биремнәргә соңыннан әйләнеп кайтырга мөмкин.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

**1-3 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

1. Ш. Галиевның «Җирдә миңа ни кирәк?» шигырендә, беренче кирәкле кешеләр дип, кемнәр әйтелә?
   1) әти-әни
   2) өй
   3) туган тел

2. Р. Миңнуллинның «Атказанган сандугач» шигырендә сандугач нишләргә ярата?
   1) җырларга
   2) биергә
   3) шигырь сөйләргә.

3. М. Әгъләмовның «Матурлык минем белән» шигырендә ни өчен автор үзен шат итеп хис итә?
   1) бишле алганга
   2) тирә-юньдә матурлык күргәнгә
   3) дуслары булганга

**4 – 6 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

4. «Минем дуслар» шигыренең авторын (исем, фамилиясен) языгыз:

   Җавап: ________________

5. Әдәби әсәр һәм аның авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз.

| | |
|---|---|
| А)«Нәүрүз килә» | 1)С.Сөләйманова. |
| Ә)«Әниләр бәйрәме» | 2). Р. Хафизова |
| В) «Сабантуй аланында» | 3) Р.Зәйдулла |

   Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

6. Н. Исәнбәтнең «Иң матур сүз» әсәре ул – 1) шигырь, 2) хикәя, 3) әкият. Санын күрсәтегез.

Җавап: _______________

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**7 – 9 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

9. Д. Аппакованың «Шыгырдавыклы башмаклар» әсәрендә төп геройның исеме ничек?

1) Гөлшат
2) Ләлә
3) Йолдыз.

8. З. Әхмәровның «Агачлар да авырый» әсәрендә корткычлар кимергәннән соң, агачларга нәрсә була?

1) корып калалар
2) яфрак яралар
3) яшел төскә керәләр

9. Ә. Баянның «Яхшылык кире кайта» әсәрендә малай каршына нәрсә очрый?

1) күрше песие Мияубикә
2) маэмай
3) тукран

**10-12 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

10. Җ. Тәрҗемановның «Тукран малае Шуктуга»н әсәренең жанрын языгыз.

Җавап: _______________

11. Язучылар һәм алар иҗат иткән әсәрләрне туры китерегез.

| | |
|---|---|
| А)Дәрҗия Аппакова | 1) «Яңа елга күчтәнәч» |
| Ә) Ринат Мөхәммәдиев | 2) «Малай һәм солдат» |
| Б) Фатих Хөсни | 3) «Йолдызкай» |

Җавап: _______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

12. Халык авыз иҗатына кайсы жанр керми? 1) хикәя; 2) мәкаль; 3) әкият. (җавапны сан белән күрсәтегез).

Җавап: _______________

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**13.1 һәм 13.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

13.1. Н. Исәнбәт «Иң матур сүз» шигырендә ни өчен әни сүзен иң матур сүз дип атый? Кыскача аңлатыгыз.

13.2. А. Алишның «Нечкәбил» әкиятендә, Нечкәбилнең кешеләр турында әйткән сүзләре хакмы?

## ҖАВАПЛАР

## Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | БАРИ РӘХМӘТ |
| 5 | 213 |
| 6 | ШИГЫРЬ |
| 7 | 1 |
| 8 | 1 |
| 9 | 3 |
| 10 | ӘКИЯТ |
| 11 | 312 |
| 12 | ХИКӘЯ |

## Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

**Рус телендә гомуми белем бирү оешмаларының**
**7 нче сыйныф татар укучыларына татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты**

## Күрсәтмә вариантка аңлатма

Татар әдәбиятыннан уку елы башында тестлар уздыру материалларының күрсәтмә варианты укучыларга һәм укытучыларга йөз тотып төзелде. Шуны истә тотарга кирәк: әлеге вариант тәкъдим ителәчәк биремнәрне тулысынча чагылдырмый. Аның төп максаты – укучыларга тест эшләүгә мөстәкыйль әзерләнү өчен юнәлеш бирү.

Күрсәтмә вариант укучыларда биремнәрнең структурасы, күләме, формасы, катлаулылык дәрәҗәсе (җиңел, уртача, авыр) турында гомуми күзаллау булдыруны күздә тота. Киңәйтелгән җавапларны бәяләү критерийлары укучыларда һәм укытучыларда бу сорауларга куелган таләпләр турында күзаллау булдыра, әзерлек процессында игътибар ителәсе мәсьәләләрне ассызыклый, укучыларга татар әдәбиятыннан тестларга әзерләнү юлын формалаштырырга, камилләштерергә ярдәм итә.

## Эшне башкару өчен күрсәтмә

Имтихан эшен башкару өчен 45 минут вакыт бирелә. Татар әдәбиятыннан тест уздыру биремнәре 15 биремне үз эченә алган 3 бүлектән гыйбарәт.

Беренче бүлектәге биремнәр лирик яки лиро-эпик әсәргә, аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның лирик яки лиро-эпик әсәргә яки шагыйрь иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, шигъри әсәрләргә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә.

Икенче бүлектәге биремнәр проза яки драма әсәренә һәм аларга бәйле теоретик төшенчәләргә караган ачык һәм ябык тестларга нигезләнеп эшләнгән. Алар укучыларның эпик яки драматик әсәргә яки әдип иҗатына бәйле фактик мәгълүматларны белүен, проза яки драма әсәрләренә хас үзенчәлекләрне аерып алуын ачыклауга йөз тотып төзелгән. Бу бүлектә А тибындагы 4 бирем, В тибындагы 3 бирем тәкъдим ителә. Җавап бирү барышында төгәл эшләү һәм күрсәтмәләрне игътибар белән уку таләп ителә.

Өченче бүлектәге биремнәр 5-8 җөмлә күләмендә киңәйтелгән җавап язуга йөз тота. Ике сорауның сайлап алып БЕРСЕНӘ генә җавап бирү сорала. Җавап язганда темадан читкә китмичә, җавапны артык киңәйтмичә формалаштыру кирәк. Әмма бу сан якынча, шартлы, җавапны тикшерү барышында аның эчтәлегенә игътибар ителә. Беренче, икенче бүлекләрдә сорауга төгәл җавап табылмый икән, авырлык тудырган сорауларны калдырып торырга, өченче өлештәге биремне үтәргә, эшләнми калган биремнәргә соңыннан әйләнеп кайтырга мөмкин.

Катлаулылык дәрәҗәсенә карап, һәр биремгә бер яки аннан артык балл куела, ахырда бөтен баллар бергә кушылып, нәтиҗә чыгарыла.

**Уңышлар телибез!**

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.** |

1. Р.Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан» шигырендә лирик герой кем?

   1) туган җирен яратучы
   2) сагыш хисендә янучы
   3) үткәннәрен сагынучы

2. Әсәрнең идеясе дип нәрсәгә әйтәбез?

   1) әсәрнең нәрсә турында булуы
   2) әсәрдә автор фикере
   3) әсәрдә куелган сорау

3. Бу шигырьләрнең кайсы туган телне ярату турында?

   1) Р.Фәйзуллинның «Туган тел турында бер шигыре»
   2) Ф.Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез»
   3) Р.Рәкыйповның «Мин яратам сине, Татарстан»

4. Кайсы әсәрдә төп геройның туган илен сагыну хисе сурәтләнгән?

   1) «Яз әкиятләре»
   2) «Сагыну»
   3) «Исемдә калганнар»

| |
|---|
| **5 – 7 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.** |

5. Ритм ярдәмендә оешкан тезмәләр бәйләме нәрсә дип атала:

   Җавап: ________________

6. Әдипләр һәм алар иҗат иткән әсәрләрне туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) Ф.Яруллин | 1)«Әбүгалисина» |
| Ә) К.Насыйри | 2) «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» |

| | |
|---|---|
| Б) Г.Рәхим | 3) «Яз әкиятләре» |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *шигырь, комедия, җыр* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Иске кара урман»
2) «Беренче театр»
3) «Пәрәмәч»

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**8 – 11 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

8. «Әбүгалисина» повестенда автор үткәргән фикер нәрсә турында?

1) Игелекле, укымышлы булу турында
2) Туган илне ярату турында
3) Аерылу сагышы турында

9. «Яз әкиятләре»нең авторы кем?

1) Г.Рәхим
2) Г.Ибраһимов
3) Г.Кутуй

10. «Беренче умырзая» әсәрендә кулланылган төп әдәби алым:

1) психологизм
2) аллегория
3) пейзаж

11. «Алмачуар» әсәрендә Закир нинди образ?

1) эпизодик герой
2) төп герой
3) ярдәмче герой

**12-14 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре**

**яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

12. Ә.Еники «Кем җырлады?» хикәясендә геройның күңел кичерешләрен тасвирлау өчен нинди алымны файдаланган?

Җавап: ___________________

13. Әсәрне һәм авторын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз:

| | |
|---|---|
| А) «Беренче театр» | 1) Г.Ибраһимов |
| Ә) «Алмачуар» | 2) Дәрдемәнд |
| В) «Кил, өйрән» | 3) Г.Камал |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

14. Тәкъдим ителгән исемлектәге әсәрләрне *повесть, комедия, хикәя* эзлеклелегендә урнаштырыгыз. Җавабыгызда алар алдына куелган саннарны үсә бару тәртибендә языгыз.

1) «Яз әкиятләре»
2) «Беренче театр»
3) «Әбүгалисина»

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**15.1 һәм 15.2. биремнәренә 5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

15.1. Ф.Яруллинның «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигырен тыңлагыз. Лирик геройның кичерешләре нинди? Тасвирлап языгыз.

15.2. Җыр нәрсә ул? Җыр – нинди жанр?

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 2 |
| 3 | 1 |
| 4 | 2 |
| 5 | СТРОФА / КУПЛЕТ |
| 6 | 213 |
| 7 | 321 |
| 8 | 1 |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 2 |
| 12 | ПСИХОЛОГИЗМ |
| 13 | 312 |
| 14 | 321 |

### Киңәйтелгән җавапларны (5-8 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары

5-8 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |

| | |
|---|---|
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |